СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №94 (7267) | 6 август, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## „Уңыш-91" пресс-группасы хәбәр итә

Районда борчак һәм уҗым культураларын җыю тулысынча тәмамланды. Сабан культураларын җыю дәвам итә. 5 нче августка ашлыкның 77 проценты теземнәргә салынды, ә 66 проценты, ягъни 35142 гектары суктырылды.

Сабан культураларын җыю да бар куәтенә алып барыла. Бүгенге көндә солының—60, ә арпаның 57 проценты җыелды.

Районда 13014 гектарны тәшкил иткән сабан бодае да бар. Аның 12 проценты, ягъни 1602 гектарыннан ашлык җыелды.

Хуҗалыклар уҗым культуралары өчен җир әзерләүгә дә игътибарны киметмиләр.

## Игенчелектә көн бурычлары:

**Якын көннәрдә бөртекле һәм сабан культуралары урып-җыюны төгәлләргә, уҗым культуралары өчен җир әзерләргә, ашламаларны җитәрлек дәрәҗәдә һәм соңармыйча әзерләп куярга, урып-җыю белән бер үк вакытта орлык әзерләүне дә алып барырга, аның югары репродукцияле перспектив һәм классны сортларын тупларга, туңга сөрүне тулы куәтенә алып барырга, чөгендер уңышын җыюга әзерләнергә.**









Рәсемнәрдә: район хуҗалыкларында кыр эшләре барышы.

## Бер колхоз хәбәрләре

### ИҢ АЛДЫНГЫЛАР

«Москва» колхозы игенчеләре урып-җыюны күтәренке кәеф белән алып баралар. Быелгы корылык елында игеннең бер бөртеген дә югалтмауга аеруча игътибар итәләр. Комбайнчылар арасында иң алдынгы булып Иван Петрович Богданов бара. Ул үзенең «Нива» комбайны белән 3300 центнер бөртекле ашлык суктырды.

Урдыру эшләре дә биредә тулы куәтен алган. Иван Федорович Максимов хуҗалыктагы урдыручыларны әйдәп бара. Ул СК-5 комбайны белән 350 гектар игеннәрне теземнәргә салды.

x x x

Урып-җыю белән бергә икенче елгы чәчүгә хәзерлек тә тукталып тормый. Бүген бу җаваплы эштә Сергей Валерьевич Чернов һәм Владимир Геннадьевич Ивановны җылы сүзләр белән әйтеп үтәргә кирәк. Аларның тырыш хезмәте белән салына киләсе ел уңышына нигез.

И. ГАФУРОВ.

## *Кыр батырларына тигезләнегез!*

## Районның ашлык суктыруда иң әйбәт күрсәткечләргә ирешкән алдынгы комбайнчылары

Беренче багана—тоткан урыны, икенче—исем-фамилиясе, өченче—хуҗалыклар исеме, дүртенче—машина маркасы, бишенче—урып-җыю башыннан суктырылган бөртек.

(Мәгълүматлар 1991 елның 5 августына).

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Абрамов В. Д. | «Восход» | ДОН-1500 | 6894 |
| 2. | Кыямов Х. К. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 6521 |
| 3. | Нилов Н. В. | Синдряков исем. | ДОН-1500 | 6100 |
| 4. | Донсков А. Е. | «Большевик» | ДОН-1500 | 5973 |
| 5. | Сафин Ә. Ә. | Ульянов исем. | ДОН-1500 | 5106 |
| 6. | Абдрахманов Р. А. | «Игенче» | ДОН-1500 | 4572 |
| 7. | Хәлимов М. Х. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 4414 |
| 8. | Матвеев В. А. | «Алга» | СК-5 | 4308 |
| 9. | Ситдыйков С. Ш. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 4286 |
| 10. | Ибраһимов Ә. И. | «Игенче» | ДОН-1500 | 4194 |
| 11. | Шәрәков Ф. Г. | «Алга» | СК-5 | 4187 |
| 12. | Бикиниев С. З. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 4050 |
| 13. | Фәттахов Ф. Ф. | «Алга» | СК-5 | 3883 |
| 14. | Гордюнин Ю. А. | «Заветы Ильича» | ДОН-1500 | 3849 |
| 15. | Вафин Р. Р. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 3805 |
| 16. | Хәсәнҗанов Н. Г. | «Чишмә» | СК-5 | 3700 |
| 17. | Нуруллин Р. Ә. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 3629 |
| 18. | Әхмәтов Ә. Б. | «Комбайн» | СК-5 | 3500 |
| 19. | Абдуллин И. Ә. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 3500 |

## *Дан флагы күтәрелә*

Район үзәгендә Дан флагы «Восход» колхозы комбайнчысы Василий Дмитриевич АБРАМОВ хөрмәтенә инде берничә тапкыр күтәрелде. Соңгы өчкөнлек нәтиҗәләре буенча Дан флагы кабат аның хөрмәтенә җилферди. Ул үзенең «ДОН-1500» комбайнында 6894 центнер ашлык суктырып, район комбайнчылары арасында әйдәп бара.

## 1991 нче ел уңышын уру алдынгылары

Беренче багана—тоткан урыны, икенче—исем-фамилиясе, өченче—хуҗалыклар исеме, дүртенче—машина маркасы, бишенче—урып-җыю башыннан күпме урдырылган (гектарларда).

Мәгълүматлар 5 нче августка.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Шәфигуллин Р. З. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 693 |
| 2. | Алиев С. Х. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 546 |
| 3. | Хәлиуллин В. Х. | «Таң» | СК-5 | 450 |
| 4. | Алексеев А. В. | «Сөлчә» совхозы | СК-5 | 408 |
| 5. | Әхсәнов С. Ш. | «Игенче» | СК-5 | 396 |
| 6. | Родионов А. В. | Синдряков исем. | СК-5 | 375 |
| 7. | Демьянов Е. М. | «Восход» | СК-5 | 360 |
| 8. | Захаров В. А. | Синдряков исем. | СК-5 | 333 |
| 9. | Максимов И. Ф. | «Москва» | СК-5 | 310 |
| 10. | Хәсәнҗанов М. Р. | «Таң» | СК-5 | 310 |
| 11. | Зиннуров Р. Р. | «Игенче» | СК-5 | 282 |
| 12. | Низамов З. Н. | Ульянов исем. | СК-5 | 280 |
| 13. | Кузьмин В. М. | «Рассвет» совхозы | СК-5 | 239 |
| 14. | Яргунов В. Д. | Мичурин исем. | СК-5 | 225 |

# ОЗЫН, ЛӘКИН КЫСКА ЮЛ

Бар иде безнең дә яшь чаклар. Бер уч борчак куырып ашаганы өчен Зәйнетдин Мусинның әнисе Минзадәне, биш-алты баласы ятим калуына карамастан, суд хөкеменә тарттылар һәм утырттылар. Шуннан ул кире кайтмады. Ә ятим балаларны әнисенең әтисе, яки балаларның бабасы Сәмигулла карт асрамага алды. Шулай ул аларга үзенең ата назын бүлеп биреп, уртак телемнәреннән артык өлеш чыгарган көннәрнең берсендә Урта Азия якларыннан бертуганнары кайтып төште һәм балаларны үз тәрбиясенә алды. Хәзер Зәйнетдин Мусин хатыны Әлфия белән «Комбайн» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында гаилә подрядында эшлиләр. Алар үз группаларындагы бозаулардан әйбәт артым алалар. Сугыш чоры балалары эштә талымсыз, тыңлаучан булдылар дип әйтәсем килә.

Элек «Комбайн» колхозы дүрт колхоз булып яшәде: «Новый путь», «Байрак», «Красная звезда», «Комбайн» колхозлары. Хәзер 13 йорты булган Рус Әмзәсе авылында ул чагында берничә урам бар иде.Менә шул авыл кешеләре ел саен бакча тутырып кәбестә үстерделәр һәм үзләреннән артып калганны дәүләткә тапшырдылар.

Мин безнең хәзерге «Комбайн» элек «Байрак» колхозы булып саналганда эшли башладым. Атлар карадым. Ул чакта план бирәләр иде, әйтик 200 бияне каплатырга. Үзебездә моңа мөмкинлек булмаганга, башка хуҗалыклар белән килешү төзедек. Шул рәвешчә нәсел үрчетү мәсьәләсе артык планда тормады һәм без бушлай хезмәт куюыбызга карамастан, хәтта иң ерак авылларга да бара идек.

Бераз тракторда да прицепщик булып хезмәт куйдым. Әлмәт МТСына унике колхоз беркетелде. Биредәге тракторлар шул колхозларга үз хезмәтен күрсәтергә тиеш булдылар. Ә тракторлар җитешми һәм аны һәрбер колхозга бер-ике көнгә генә биреп торалар иде. Кыска вакыт эчендә без ничек булса да ватылусыз эшләргә тырыштык. Үзегез уйлап карагыз, элек бит тракторлар утын ягып эшләтелде. Ягулык өчен күп кенә утын агачы әзерлибез һәм сөрүне үз вакытында бетерү өчен бернинди ялсыз, алмашсыз эшлибез. Шунысы да бар, чәчкечнең һәрбер сошнигын майлап чыгабыз. Юкса, кабул итмиләр.

Җир сөрү дигәч тә, айһай кыенга туры килде ул безгә. Тракторчылар Сәгыйть Хөббуллин, Гайфи Сәгъдиев 5 корпуслы сабан өстенә беркетелгән руль белән идарә итеп сукаладылар җирне. Сыртлырак җиргә җиткәч, суканы күтәртергә, ә сырт беткәч төшерергә кирәк. Әнә шулай әзерләнде икмәк өчен җир. Һәрбер тракторчыга көненә 7,2 гектар җир сукаларга норма бирелде. Шунысы да бар, прицепщик эше никадәрле авыр булса да, анда эләгеп булмый иде. Иң сау-сәламәтләрне һәм тырыш, түзем кешеләрне генә сайлап алдылар.

Хәзерге яшьләр ник болай эшкә атлыгып тормыйлар икән? Берәүнең җир сукалаганын карап торырга туры килде: аңа көненә 4,2 гектар җир сөрергә норма бирелгән. Ә ничек эшли?! Алгы өлеше тирән, артны сай алдыра. «Ник болай сукалыйсың?» дим. «Ә мине килеп караучы юк», ди бу. Безнең арттан кем дә булса күзәтеп йөрдеме? Берәү дә килмәде. Бу бит үз намусыңда. Яхшы сукаласаң да, сукаламасаң да ягулыкны яндырасың, көн үтә. Шулай булгач, эшлә намусың кушканча, берәү дә бәйләнмәс.

Үземнең үткәнемне күзаллыйм. 30 ел товарлыклы-сөтчелек фермасында хезмәт куйдым, бер генә мәртәбә дә отпуска алмадым. Дөрес, авырып китү сәбәпле бер мәртәбә санаторийга барып ял итеп кайттым. Аттан егылып төшеп кулымны имгәткән идем. Хәзер килеп сорагыз, Норлатта Сабантуй кайда үткәрелә дип—әйтеп бирә алмыйм.

1958 елларда сарыкчылык һәм куян фермаларында да хезмәт куйдым. Сарыкларны 1800 башка хәтле җиткергән чагыбыз булды. 1963 елда симертү өчен икенче бригадага 50 баш буаз таналар кайтарылды. Шунысын да әйтим, безнең хуҗалыкка куян, сарык, бозау сорап килүчеләр булды, ләкин һәрберсен кире борып җибәрә торган идем. Хәзер уйлап куям: ярый әле яшьлегем белән шундый тайгак юлга басмадым, дим.

Ферма хезмәтчәннәре белән без һәрчак уртак тел таптык. Беркайчан да, берәү өстеннән дә шикаять белән колхоз идарәсенә бармадым. Килеп чыккан аңлашылмаучанлыкларны үзара хәл итәргә тырыштык. Кайберәүләр миңа, син үз коллективыңны яклыйсың, дип тә әйткәләделәр.

Үз гомеремдә тәмәке тартмадым, аракы эчмәдем. Ун колхоз рәисе белән эшләдем. Устав бер булса да, характерлары төрле иде. Ләкин ызгышмадым, мәсьәләләрне сабыр гына хәл итә килдек.

Фонарьлар тотып, төннәр буе бозаулаган сыерлардан бозаулар алып йөрүне һәм аларны эчәргә өйрәтүне сез генә түгел, хәтта бүгенге ферманың яшь терлекчеләре дә күз алдына китерә алмый әле.

Ферма хезмәтчәннәре өчен эш шартлары хәзер күпкә җиңеләйде. Гөрләп Ильич утлары яна, сөтне машина сава, азыкны техника китерә...

Сугыш башланганда, әтием Хатыйп колхоз рәисе булып эшләде. Алар—беренче күмәк хуҗалык оештыручылар. Хуҗалыкка дуңгызларны да беренче мәртәбә алар алып кайтты. Бик кыен көннәр иде ул. Берсендә әти коммунистлар белән бәхәсләшә: «Бу кырда гектарыннан 8 центнер ашлык алыначак», ди. Ә тегеләре, 12 центнер диләр. Шуннан эш судка кадәр барып җитә. Аны колхозга каршы контрагитация алып баруда гаеплиләр. Әти өч ел Мәскәү янында режим белән утырып чыга. Аның җиз таз белән авыз гармуны алып кайтуын әле дә хәтерлим. Ә теге ашлык ничек булды дисезме? Нәкъ әти әйткәнчә, килосы килога туры килә.

1941 елның октябрь аенда әтием сугышка китте. 1944 елга хәтле әле ул безгә хатлар язып торды. Берсендә, медсанчастькә яралыларны кабул итәбез, дигән. Шуннан хәбәрсез югалды. Әнием Гайшә дә авыр сугыш елларында дөнья куйды. Энем Хәсип кечкенә иде әле. Өлкән бала буларак, тормышның йөген башлап миңа җигелеп тартырга язган икән. Гаиләне дә шуның өчен иртә кордым. Дүрт бала тәрбияләп үстердек.

1951—54 елларда ясалма орлыкландыручы хезмәтен башкардым. Бу елларда әле таналарны сатып алмыйлар иде. Яхшы сыерлардан туган бозауларга тәңкәләр асып аларны аерып куйдык. Бары 3—4 центнерга җиткән таналарны гына каплаттык.

Яшь бозауларга кисеп алына торган кесәл пешердек. Ботка пешерер өчен 200 центнер борчак, солы, бодай бирелде. 1973 елда һәр сыердан 2240 килограмм урынына 2304 килограмм сөт саудык.

1976 елда зоотехник таныклыгы алдым, машина белән саву мастерына имтихан тоттым һәм аны «5»легә тапшырып, 2 нче класслы белгеч булдым.

1986 елда безнең товарлыклы-сөтчелек фермасы һәр сыердан 3 мең килограммнан күбрәк сөт сауды. Унберенче бишьеллыкта республика комсомол-яшьләр коллективлары арасында җәелдерелгән ярышларда җиңеп чыктык һәм шуның өчен күчмә Кызыл байрак белән бүләкләндек.

Мине хезмәттәге күрсәткечләрем өчен «Почет билгесе», «Халыклар дуслыгы» орденнары, хуҗалыкның «Почетлы кешесе» исеме һәм бик күп төр Мактау грамоталары белән бүләкләделәр.

Тик менә «Хезмәт ветераны» медале генә ни сәбәпледер һаман кайтып җитмәде.

Озын, авыр юлны үттем. Бу минем гомер юлым. Бу юл күпләрне көтә: озын юлның авырлыкларын җиңеп үтсәгез, соңыннан ул кыска, җиңел булып тоелыр.

**Х. ХӘБИБРАХМАНОВ.**
Иске Әмзә авылы.

# Үз эшләренең осталары

Басуларда гына түгел, хәзер ашлык кабул итү пунктларында да киеренке хезмәт чоры.

Норлат элеваторына бу көннәрдә туктаусыз машиналар агыла. Алар бирегә китергән икмәкне элеватор эшчеләре тиз арада сортларга аералар һәм кайсын кая озаталар.

Зинаида Евграфовна Морозова белән Валентина Петровна Вертушкина кече габаритлы универсаль катнаш азык заводында инде байтак еллар эшлиләр. Алар катнаш азык составына ашлык, тоз, акбур һәм башкалар кертелгән чимал биреп торалар. Эш монда җиңелләрдән түгел, кул хезмәте киң кулланыла. Аннан, тузан эчендә эшләгәнгә алар цехы зарарлылардан да санала. Ләкин хатын-кызлар мондый шартларга гына күнеккәннәр күрәсең, зарлану дигән нәрсәне белмиләр. Ни хәл итәсең, уңай эш шартлары тудыру өчен әле байтак вакыт кирәк булыр. Ә аның тууын кул кушырып көтеп утырып булмый бит инде. Менә шуны аңлаганга да, эштән-эшкә сайланып йөрмиләр алар.





Рәсемнәрдә: элеваторның кече габаритлы универсаль катнаш азык заводы эшчеләре Зинаида Евграфовна Морозова һәм Валентина Петровна Вертушкинаны күрәсез.

# Ярдәмгә килдек

Туган якның кырлары. Шушы сүзләрдән дә газизрәк сүзләр юк сыман минем өчен. Хәер, бер караганда мин профессиям буенча үзем игенче дә түгел. Ләкин урак вакыты җиттеме, җәйге ялны онытып комбайнга ашыгам. Мәктәптә хезмәт фәнен укыткангамы, тик утыра алмыйм. Кыр корабына утырганга быел җиденче сезон була инде. Комбайн дисәң дә, тышкы яктан гына матур күренә ул. Тузан эчендә, май һәм дегеткә буялып, бер таңнан кара төнгәчә эшләүләре бик кыен. Шунлыктан комбайнга аеруча түземнәр һәм сабырлар гына килә дә.

Безнең «Родина» колхозында минем кебек укытучы-комбайнчы тагын бар: Рунар Рәфыйкович Галиуллин. Ул география укытучысы. Аның белән бергәләп борчакта һәм арышта эшләдек, хәзер арпада. Әнә шулай без туган колхозыбызга булдыра алганча үзебездән ярдәм күрсәтәбез.

**Н. САНДИМИРОВ.**
«Родина» колхозы.

# Бишенче—хезмәт чиреге

Кычытканлы. Районыбызның иң матур табигатьле авылларыннан берсе. Чиста урамнары, ямьле йортлары, ул йортларның нурлы тәрәзәләре, тәрәзә төбендәге яраннары белән күңелдә кала торган авыл бу. Янәшә генә Мораса елгасы ага. Ә кешеләре—искиткеч яхшы күңелле, ярдәмчел һәм хезмәт сөючән кешеләр яши монда. Без аларны аз вакыт эчендә яратырга өлгердек. Мондагы кирпеч заводында бер ай дәвамында безнең XI-А классы эшләде һәм ял итте.

Килеп төшүнең беренче минутларыннан ук без «Татарстан» колхозы җитәкчелегенең игътибарын һәм кайгыртуын тойдык.

Беренче көнне безне колхоз председателе Ж. З. Нургалиев, партоешма секретаре Р. А. Насыйбуллин, авыл Советы председателе Ф. Н. Нургалиев каршылады. Алар безгә күңелле ял һәм файдалы хезмәт итүебезне теләделәр. Без үзебезнең алда мөһим һәм кирәкле эш башкару бурычы торганлыгын шунда ук аңладык.

Кунакчыл Ләмига апа Нәбиуллина безне үзебез яшәячәк чип-чиста өйгә озатты. Урнашып алгач, бераз дулкынланып, кирпеч заводына юнәлдек.

Безне монда завод директоры Р. М. Шәйхиев көтә иде. Безне кирпеч сугуга өйрәтү өчен Ә. И. Исхакова һәм А. Г. Локмановка күпме сабырлык, түземлек кирәк булгандыр. Бер күрүдә генә эшне өйрәнеп бетереп булмый шул. Берәр ягы килеп чыкмаса, сүзне озынга сузмый гына безгә Әфкать абый ярдәмгә килә иде. Әкренләп эшне үзләштердек без.

Эшләве кызык икән. Ике бригада (Р. Атауллин һәм Д. Чеплаков җитәкчелегендә) бер-берсе белән ярышып эшләделәр. Җәйге хезмәт практикабыз вакытында без 160 меңнән артык кирпеч суктык.

Эштән соң колхоз ашханәсенә—үзебезнең әниләрдәй кайгыртучан, ягымлы Әминә апа Мингалимова һәм Сания Галиуллина янына йөгерә идек. Алар пешергән токмачлы ашның, авызда эри торган коймакларның һәм гаҗәеп авыл катыгының тәмен сүз белән генә аңлатып булмый.

Колхозның культура йорты. Бусы инде үзе бер оҗмах: иркен, ямьле тамаша залы, бай китапханә һәм аның киң күңелле хуҗасы Д. Р. Мансурова, бильярд һәм шахмат өстәлләре куелган фойе. Кичләрен дискотекага йөри идек.

Бер айның үткәне сизелми дә калды. Хушлашыр чак та җитте. Дусларыбыз җыелышып озатырга килгәннәр иде. Күңелдә бераз моңсулык та бар. Сау бул, Кычытканлы. Кабат очрашканга кадәр сау бул!

**Л. СИДОРЕНКО,**
беренче мәктәп.

